ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; 2013, № 10), түбәндәге эчтәлекле $7^1$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$7^1$ статья. **Электрон документлар рәвешендәге граждан хәле актлары язмаларын саклау урыны**

Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелгән электрон документлар рәвешендәге граждан хәле актлары язмалары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органының мәгълүмат системасында саклана.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 07 мае
№ 27-ТРЗ